**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2368**
**28.03.2025**

Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21, 5.22 пунктлары, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2024 елның 27 мартында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2024 елның 22 мартындагы 1774 номерлы Башкарма комитет Карары;

2) 2024 елның 31 июлендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2024 елның 22 мартындагы 1774 номерлы Карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 23 июлендәге 4809 номерлы Карары;

3) 2025 елның 15 гыйнварында Татарстан Республикасы рәсми хокукый

мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2024 елның 22 мартындагы 1774 номерлы Карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 10 гыйнварындагы 10 номерлы Карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы В.Х. Харисов

Башкарма комитетның
2025 елның 28 мартындагы
2368 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» МУП
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге (бер сеанс) | Чик тариф сумнарда |
|---|---|---|---|
| Балалар аттракционнары | | | |
| 1. | Карнавал | 3 мин | 65 |
| 2. | Кыңгырау | 3 мин | 65 |
| 3. | Юнга | 3 мин | 65 |
| 4. | Рельстагы джиплар | 3 мин | 65 |
| 5. | «Мультфильм геройлары» мультпоезды | 3 мин | 90 |
| 6. | «Миниаэропорт» каруселе | 3 мин | 80 |
| 7. | Кояшкай | 3 мин | 65 |
| 8. | «Җилкәй» балалар чылбыры | 3 мин | 90 |
| 9. | Җиләк-җимешләр | 3 мин | 145 |
| 10. | Батут | 10 мин | 145 |
| 11. | Күңелле утыргыч | 3 мин | 145 |
| 12. | Индеецлар елгасы | 3 мин | 90 |
| 13. | Мини-джет | 3 мин | 90 |
| 14. | «Аквазорб» су шары | 3 мин | 180 |
| 15. | Диңгездә ау | 3 мин | 180 |
| 16. | Балалар өчен чылбырлы карусель | 3 мин | 130 |
| 17. | Көнгерә | 3 мин | 145 |
| Гаилә аттракционнары | | | |
| 18. | Көлке бүлмәсе | - | 25 |
| 19. | Тир | 5 тапкыр ату | 65 |
| 20. | Экспресс-Шоссе | 10 мин | 120 |
| 21. | Орбита | 3 мин | 145 |
| 22. | Күңелле таулар | 3 мин | 170 |
| 23. | «Сафари» тиры | 3 мин | 90 |
| 24. | Автодром (1 машина) | 3 мин | 210 |
| 25. | Судагы көймәләр (1 көймә) | 3 мин | 200 |
| 26. | Күзәтү тәгәрмәче | 7 мин | 215 |
| 27. | Күбәләк корты | 3 мин | 120 |
| 28. | Аккошлар (1 кабина) | 3 мин | 200 |
| 29. | Туй каруселе | 3 мин | 130 |
| 30. | ФутуРифт виртуаль чынбарлык | - | 190 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 31. | Электропоезд | 9 мин | 120 |
| 32. | Чәй йоласы | 6 мин | 175 |
| Экстремаль аттракционнар | | | |
| 33. | Өермә | 3 мин | 130 |
| 34. | Сюрприз | 3 мин | 90 |
| 35. | Вальс | 3 мин | 210 |
| 36. | Астронавт | 3 мин | 210 |
| 37. | Оча торган тәлинкә | 3 мин | 210 |
| 38. | Энҗе бөртеге | 3 мин | 210 |
| 39. | Зодиак | 3 мин | 210 |
| 40. | Оча торган голландияле | 3 мин | 210 |
| 41. | Стелла-Магнетик | 3 мин | 210 |
| 42. | Хип-Хоп | 3 мин | 210 |
| 43. | Биоробот | 3 мин | 210 |
| 44. | Чылбырлы карусель | 9 мин | 210 |
| Спорт һәм ял өчен прокатка инвентарь бирү буенча хезмәтләр | | | |
| 45. | Тимераяклар | 1 сәгать | 160 |
| 46. | Тимераяклар (14 яшькә кадәрге балалар) | 1 сәгать | 120 |
| 47. | Фигурист ярдәмчесе | 1 сәгать | 120 |
| Сервис хезмәтләре | | | |
| 48. | Бәдрәф | 1 тапкыр керү | 10 |
| 49. | Парк картасы | 1 данә | 50 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева